СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

21.06.2011 № 19/6

На №__________от__________

# КАРАР

**Тукай муниципаль районының бердәм конкурс комиссиясе һәм бердәм аттестация комиссиясе турында нигезләмәләрне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2003 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы, Тукай муниципаль районы Советының 2019 елның 22 февралендәге вн/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә, кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында төзелгән килешүләр нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча бердәм комиссия төзергә (алга таба – Бердәм конкурс комиссиясе).

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Бердәм аттестация комиссиясен төзергә (алга таба – Бердәм аттестация комиссиясе).

2. Расларга:

Тукай муниципаль районының бердәм конкурс комиссиясе турында нигезләмәне һәм аның составын;

Тукай муниципаль районының бердәм аттестация комиссиясе турында нигезләмәне һәм аның составын.

3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесенә, район Башкарма комитетының персонал белән эшләү бүлегенә Бердәм конкурс комиссиясе һәм Бердәм аттестация комиссиясе эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Тукай муниципаль районы сайтында урнаштырылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.М. Камаев

Тукай муниципаль районы Советының 2022 елның 21 мартындагы 19/6 номерлы карарына 1 кушымта

## Тукай муниципаль районының бердәм конкурс комиссиясе турында нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бердәм конкурс комиссиясенең (алга таба - комиссия) төп бурычларын һәм эш тәртибен билгели.

Комиссия Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында һәм килешү буенча район җирлекләре җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларына конкурслар үткәрергә хокуклы.

1.2. Комиссиянең шәхси составы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы карары белән раслана.

1.3. Комиссия составы комиссия кабул иткән карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыклары барлыкка килү мөмкинлеге булмаслык итеп формалаштырыла.

1.4. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына, әлеге Нигезләмәгә һәм башка муниципаль норматив-хокукый актларга таяна.

### 2. Комиссиянең бурычлары

2.1. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар оештыру һәм үткәрү.

### 3. Комиссиянең хокуклары һәм бурычлары

3.1. Комиссия хокуклы:

дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

комиссия эшенә билгеләнгән тәртиптә белгечләр җәлеп итәргә;

районның җирле үзидарә органнарына үз эшчәнлеген оештыру белән бәйле тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр кертергә.

3.2. Комиссия бурычлы:

җирле үзидарә органнарына үткәрелә торган эш турында хәбәр итәргә.

### 4. Комиссия эшен оештыру

4.1. Комиссиягә - рәис, ә ул булмаганда, комиссия рәисе урынбасары җитәкчелек итә.

4.2. Комиссия утырышлары кирәк булган саен үткәрелә.

4.3. Комиссия утырышы аның әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше булганда хокуклы.

4.4. Утырышның көн тәртибе һәм карар проектлары җаваплы секретарь тарафыннан әзерләнә һәм барлык комиссия әгъзаларына утырышка кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

4.5. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

4.6. Комиссия утырышын аның рәисе яки ул вәкаләт биргән зат алып бара.

4.7. Комиссия утырышына, аның әгъзаларыннан тыш, башка затлар да чакырылырга мөмкин. Утырышта катнашучылар составы комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә.

4.8. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәләр комиссиянең җаваплы секретаре тарафыннан имзалана һәм комиссия рәисе яисә аны алмаштыручы зат тарафыннан раслана. Рәсмиләштерелгән утырыш беркетмәләре өч көн эчендә барлык комиссия әгъзаларына һәм кызыксынган оешмаларга җибәрелә.

4.9. Утырыш беркетмәләрен алып бару, рәсмиләштерү һәм җибәрү комиссиянең җаваплы секретаренә йөкләнә.

Тукай муниципаль районы Советының 2022 елның 21 мартындагы 19/6 номерлы карарына 2 кушымта

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә бердәм конкурс комиссиясе составы

Комиссия рәисе:

| | |
|---|---|
| Закиров Рөстәм Илдус улы | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башлыгы урынбасары. |

Комиссия рәисе урынбасары:

| | |
|---|---|
| Галишина Гөлназ Рәис кызы | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе. |

Комиссиянең җаваплы секретаре:

| | |
|---|---|
| Сәлимова Лилия Фәнзир кызы | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының персонал белән эшләү бүлеге башлыгы. |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Бузина Нәзирә Камил кызы | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге башлыгы; |
| | Конкурс игълан ителгән вакантлы вазыйфа булган район авыл җирлеге башлыгы; |
| | Бәйсез экспертлар: |
| | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы ветераннар (пенсионерлар) һәм инвалидлар оешмасы рәисе; |
| | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең башлангыч профсоюз оешмасы рәисе. |

Тукай муниципаль районы Советының 2022 елның ___ мартындагы ___ номерлы карарына 3 кушымта

## Тукай муниципаль районының бердәм аттестация комиссиясе турында нигезләмә

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бердәм аттестация комиссиясенең (алга таба - комиссия) төп бурычларын һәм эш тәртибен билгели.

Комиссия Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында һәм килешү буенча район җирлекләре җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләүне үткәрергә хокуклы.

1.2. Комиссиянең шәхси составы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы карары белән раслана.

1.3. Комиссия составы комиссия кабул иткән карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыклары барлыкка килү мөмкинлеге булмаслык итеп формалаштырыла.

1.4. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына, әлеге Нигезләмәгә һәм башка муниципаль норматив-хокукый актларга таяна.

### 2. Комиссиянең бурычлары һәм функцияләре

2.1. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

җирле үзидарә органнары өчен, шул исәптән ведомство карамагындагы бүлекләр өчен кадрлар әзерләүне, яңадан укытуны һәм квалификацияләрен күтәрүне гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен аттестацияләүне үткәрүне оештыру;

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең квалификация имтиханын үткәрүне оештыру;

2.2. Йөкләнгән бурычларны тормышка ашыру максатында комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:

муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләүне оештыра;

муниципаль хезмәткәрләргә класс чины бирү өчен квалификация имтиханын үткәрүне оештыра.

### 3. Комиссиянең хокуклары һәм бурычлары

3.1. Комиссия хокуклы:

дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

комиссия эшенә билгеләнгән тәртиптә белгечләр җәлеп итәргә;

районның җирле үзидарә органнарына үз эшчәнлеген оештыру белән бәйле тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр кертергә.

3.2. Комиссия бурычлы:

җирле үзидарә органнарына үткәрелә торган эш турында хәбәр итәргә.

4. Комиссия эшен оештыру

4.1. Комиссиягә - рәис, ә ул булмаганда, комиссия рәисе урынбасары җитәкчелек итә.

4.2. Комиссия утырышлары кирәк булган саен үткәрелә.

4.3. Комиссия утырышы аның әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше булганда хокуклы.

4.4. Утырышның көн тәртибе һәм карар проектлары җаваплы секретарь тарафыннан әзерләнә һәм барлык комиссия әгъзаларына утырышка кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

4.5. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

4.6. Комиссия утырышын аның рәисе яки ул вәкаләт биргән зат алып бара.

4.7. Комиссия утырышына, аның әгъзаларыннан тыш, башка затлар да чакырылырга мөмкин. Утырышта катнашучылар составы комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә.

4.8. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәләр комиссиянең җаваплы секретаре тарафыннан имзалана һәм комиссия рәисе яисә аны алмаштыручы зат тарафыннан раслана. Рәсмиләштерелгән утырыш беркетмәләре өч көн эчендә барлык комиссия әгъзаларына һәм кызыксынган оешмаларга җибәрелә.

4.9. Утырыш беркетмәләрен алып бару, рәсмиләштерү һәм җибәрү комиссиянең җаваплы секретаренә йөкләнә.

Тукай муниципаль районы Советының 2022 елның ___ мартындагы ___ номерлы карарына 4 кушымта

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының бердәм аттестация комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе: | |
| Закиров Рөстәм Илдус улы | Татарстан Республикасының Тукай муниципаль районы Башлыгы урынбасары. |
| Комиссия рәисе урынбасары: | |
| Галишина Гөлназ Рәис кызы | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе. |
| Комиссиянең җаваплы секретаре: | |
| Сәлимова Лилия Фәнзир кызы | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының персонал белән эшләү бүлеге башлыгы. |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Бузина Нәзирә Камил кызы | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге башлыгы; |
| | Хезмәткәрләренә карата аттестация үткәрелгән район авыл җирлеге башлыгы; |
| | Бәйсез экспертлар: |
| | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы ветераннар (пенсионерлар) һәм инвалидлар оешмасы рәисе; |
| | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең башлангыч профсоюз оешмасы рәисе. |